**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ**
**РАЙОН СОВЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

**СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

Тел.:+7 (84365) 2-30-50, факс: (84365) 2-30-50,, e-mail: biektau@tatar.ru, www./vysokaya-gora.tatarstan.ru

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**

**6 декабрь 2019 ел** **№ 336**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджетыннан авыл җирлекләре бюджетларына хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыру буенча вәкаләтләрне тормышка ашыруга субвенцияләр бирү Кагыйдәләре турында**

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 142 статьясы нигезендә, Биектау муниципаль районы Советы,

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджетыннан авыл җирлекләре бюджетларына хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыру буенча вәкаләтләрне тормышка ашыруга субвенцияләр бирү Кагыйдәләрен расларга.

2. Әлеге карарның нигезләмәләре Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru), шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль бермәлекләр рәсми порталында Биектау муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникацияләр челтәрендә http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адресы буенча бастырылганнан соң (халыкка җиткерелгәннән соң) законлы көченә керә һәм 2020 елга һәм 2021, 2022 еллар план чорына бюджетлардан башлап, Биектау муниципаль районы бюджетын төзегәндә һәм башкарганда килеп туган хокук мөнәсәбәтләренә карата кулланыла.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Биектау муниципаль районы Советының бюджет, финанслар һәм икътисади сәясәт буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет Рәисе,
муниципаль район Башлыгы Р.Г.Кәлимуллин

Кушымта

Расланган
Биектау муниципаль районы
Советы карары белән
06.12.2019 № 336

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджетыннан авыл җирлекләре бюджетларына хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыру буенча вәкаләтләрне тормышка ашыруга субвенцияләр бирү Кагыйдәләре**

1. Әлеге Кагыйдәләр Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджетыннан Биектау муниципаль районы авыл җирлекләре бюджетларына хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыру буенча вәкаләтләрне тормышка ашыруга субвенцияләр бирү (алга таба – субвенцияләр, җирлекләр) максатларын, тәртибен һәм шартларын билгели.

2. Субвенцияләр хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыру буенча вәкаләтләрне тормышка ашыру максатларында җирлекләр бюджетларына биреләләр.

3. Җирлекләр бюджетларына субвенцияләр бирү чыгымнарын финанс белән тәэмин итү чыганагы булып Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган хәрби комиссариатлары булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен федераль бюджеттан субвенцияләр тора.

4. Әлеге Кагыйдәләр нигезендә бирелә торган бюджет акчаларын баш бүлүче булып Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты (алга таба – Башкарма комитет) тора.

5. Җирлек бюджетына субвенцияләр күләме “Татарстан Республикасы муниципаль районнарының җирле үзидарә органнарына хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен муниципаль район составына керүче җирлекләр бюджетларына субвенцияләр исәпләү һәм бирү буенча Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында”, 2006 елның 11 декабрендәге 78-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 нче кушымтасы нигезендә, муниципаль район бюджетыннан хәрби комиссариатлары булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыру буенча вәкаләтләрне тормышка ашыру өчен җирлек бюджетына субвенция күләмен билгеләү Методикасы нигезендә билгеләнә.

6. Муниципаль район составына керүче җирлекләр бюджетларына субвенцияләрне бүлү Биектау муниципаль район Советының билгеле финанс елына һәм план чорына муниципаль район бюджеты турындагы карары белән раслана.

7. Субвенцияләр билгеле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре һәм Башкарма комитет билгеләнгән тәртиптә әлеге Кагыйдәләрнең

2 пунктында каралган максатларга бирелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә җирлекләр бюджетларына бирелә.

8. Субвенцияләр түбәндәге чыгымнарны тормышка ашыру өчен җирлекләр бюджетларына бирелә:

хезмәткә түләү фондына тиешле түләүләрне дә кертеп, хәрби-исәп хезмәткәрләренә хезмәт хакы түләү;

биналарны арендалаган өчен түләү;

элемтә хезмәтләре өчен түләү;

транспорт хезмәтләре өчен түләү;

командировка чыгымнары;

коммуналь хезмәтләр өчен түләү;

җиһаз, инвентарь, оргтехника, элемтә чаралары, чыгым материаллары белән тәэмин итү.

9. Субвенцияләрне тоту Татарстан Республикасы буенча Федераль казначылык идарәсе территориаль органнарының (алга таба – Казначылык), җирлек бюджетлары үтәлешенә касса хезмәте күрсәтү өчен ачык булган шәхси счетлар аша тормышка ашырыла.

10. Башкарма комитет Казначылыктан финанслауның иң чик күләмнәрен билгеләү өчен чыгымнар расписаниесен алганнан соң, җиде эш көне эчендә Казначылыкка субвенцияләр исәбеннән җирлекләр бюджетларына субвенцияләр күчерү өчен касса чыгымына гариза бирә.

11. Җирлекләрнең җирле үзидарә органнары квартал саен, хисап периодыннан соң килүче айның 5 нче числосыннан да соңга калмыйча, Башкарма комитетка, хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыру буенча вәкаләтләрне тормышка ашыру белән бәйле җирлекләр бюджетларының чыгымнары турында хисап тәкъдим итәләр, аларның финанс тәэмин итү чыганаклары булып, Россия Федерациясе Икътисад министрлыгы тарафыннан, Россия Федерациясе Оборона министрлыгы белән килештереп билгеләнгән форма буенча субвенцияләр тора.

12. Башкарма комитетка тапшырыла торган мәгълүматларның дөреслеге өчен җаваплылык җирлекләрнең җирле үзидарә органнарына йөкләнелә.

13. Субвенцияләр бирү шартларын бозган очракта, тиешле акчалар Россия Федерациясе бюджет законнарында билгеләнгән тәртиптә муниципаль район бюджеты керемен‌ә күчерелергә тиеш.

14. Субвенцияләр бирү елыннан соң килүче елның 1 гыйнварына билгеләнмәгән субвенцияцияләрнең калган өлеше, Россия Федерациясе Бюджет кодексында билгеләнгән таләпләр нигезендә, Биектау муниципаль районы бюджеты керемен‌ә кире кайтарылырга тиеш.

15. Субвенцияләр максатчан характерга ия һәм әлеге Кагыйдәләрнең 2 пунктында күрсәтелгәннәрдән тыш, башка максатларда кулланыла алмый.

16. Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты һәм финанс-бюджет органы субвенцияләрнең максатчан кулланылышын закон нигезендә контрольдә тота.